КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 сентябрь г.Казань № 850

2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакында

2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турындагы, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакындагы докладларны тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын хупларга.

2. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын исәпкә алырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 2021 елның 30 сентябренә кадәр «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта тапшырыла торган документларны һәм материалларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

4. «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә 2021 елның 30 сентябренә кадәр «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин